СОВЕТ ОТАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октябрьская, д.17, с. Отарка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422180

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОТАРКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Октябрь ур., 17 нче йорт, Отарка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422180

тел.(факс): (85563) 3-74-77; e-mail: Otar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
«18 » сентября 2019 ел

Карар
№1-52

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге Советы К А Р А Р К А Б У Л И Т Т Е:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

« Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Отарка авылының Нократ Яр буе, Октябрь, Гражданская, Пролетарская, урамнарындагы юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, җәю, эшләр өчен килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

-“Пятилетка” совхозы поселогындагы суэтем башнясы коймасын урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-“Пятилетка” совхозы поселогындагы су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау (ремонт сетей водоснабжения) (материал, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- “Пятилетка” совхозы поселогы, Отарка авылы урамнары юлларын кардан чистарту;

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башлыгы Х.М. Минникаевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Х.М.Минникаев